**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июль № 501

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче; 2015 ел, 22 декабрь, 984 нче; 2016 ел, 31 март, 186 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына министрның алты урынбасары, шул исәптән бер беренче урынбасары булуны рөхсәт итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.31 – 3.3.33 нче пунктлар өстәргә:

«3.3.31. Татарстан Республикасы территориясендә башкарылган террорчылык акты нәтиҗәсендә зыян күргән затларны социаль тернәкләндерүне оештыру һәм тәэмин итүдә катнаша.

3.3.32. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары террорчылыкка каршы тору чараларын тормышка ашырганда үзара хезмәттәшлекне көчәйтү максатларында, әлеге органнар үткәрә торган укытуларда катнаша.

3.3.33. Министрлыкта, аның территориаль органнарында һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләрендә Татарстан Республикасы милке булган һәм оператив идарә итү хокукында Министрлыкка һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә беркетелгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышына таләпләрнең үтәлүен оештыра һәм тәэмин итә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.2[1] нче пункт өстәргә:

«Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\501.doc